| | |
|---|---|
| СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

3.11.2020 пос. Октябрьский № 3-19

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль - хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» 2020нче елның 6нчы августындагы 658нче номерлы карары, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советының
2020нче елның 3нче ноябреннән
3-19нчы номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет сәркатибе | 15292 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының 2020нче елның 3нче ноябреннән 3-19нчы номерлы карарына

12нче кушымта

Октябрьский авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 15759 |

2. Әлеге карар 2020нче елның 1нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов